Шәһәр күләмендә Татар халкы һәм Татарстан тарихы фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
9 нчы сыйныф

Эш вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 62

Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз.

1. Казан губернасы ничәнче елда оеша? (1 балл)

А) 1708 елда Б) 1714 елда В) 1718 елда Г) 1719 елда
Җавап: _____

2. XVIII гасырда Казанда иң зур сәнәгать оешмасын күрсәтегез: (1 балл)

А) Адмиралтейство Б) Постау (сукно) мануфактурасы
В) Дары заводы Г) Сабын кайнату заводы
Җавап: _____

3. XIX гасырда Казан губернасында сәүдә әйләнешендә беренче урынны нәрсә алып торган? (1 балл)

А) Күн Б) Сабын В) Икмәк Г) Бал
Җавап: _____

4. Татарлардан беренче Казан университеты профессоры: (1 балл)

А) Ибраһим Хәлфин Б) Сәгыйт Хәлфин
В) Хөсәен Фәезханов Г) Габдүш Баһапов
Җавап: _____

5. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында Казан төбәгендә яшәүче татарларның күпчелеге крестьяннарның кайсы төренә караган? (1 балл)

А) Патша гаиләсе (удел) крестьяннары
Б) Алпавыт крестьяннары
В) Дәүләт крестьяннары
Җавап: _____

6. Парижда Сорбонна университетын тәмамлаган беренче татарлар: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 балл, иң югары 2 балл)

А) Садри Максуди Б) Каюм Насыйри
В) Йосыф Акчура Г) Галимҗан Баруди
Җавап: _____

7. Казан губернасында стеарин-химик һәм сабын заводы хуҗалары кайсы династия вәкилләре булган? (1 балл)

А) Алафузовлар Б) Крестовниковлар
В) Юнусовлар Г) Апанаевлар
Җавап: _____

8. 1781-1855 елларда Казан татар бистәләренең үзидарә органы: (1 балл)

А) Земство Б) Татар суд йортлары
В) Якташлык җәмгыяте Г) Татар ратушасы
Җавап:_____

9. Тарихи вакыйгаларны һәм даталарны туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 балл, иң югары 10 балл).

1) Казанда дворян кызлары өчен Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты ачыла	А) 1851
2) Казанда А.Н. Свешниковның чуен кою заводы эшли башлый	Б) 1841
3) Каюм Насыйри тарафыннан нәшер ителә торган беренче татар календаре чыга башлый	В) 1809
4) Казан университеты типографиясенә нигез салына	Г) 1871
5) «Тәрҗеман» газетасы чыгарыла башлый (Бакчасарай шәһәре)	Д) 1883

Җавап:

1	2	3	4	5

10. Тормышлары һәм эшчәнлекләре Казан төбәге белән бәйле булган күренекле шәхесләрнең исемнәрен тасвирламалары белән туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 балл, иң югары – 10 балл)

Төшенчә	Тасвирлама
1) Лобачевский Николай Иванович	А) астроном, Казан астрономия фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Яктырткычларның үлчәнгән биеклеге буенча җирле вакытны билгеләүнең үзенчәлекле алымын эшли
2) Лихачёв Андрей Фёдорович	Б) математик, геометр, евклид булмаган геометрияне уйлап табучы. Университет ректоры булганда, аның җитәкчелегендә китапханә, анатомия театры, обсерватория, клиника биналары, оранжерея төзелә
3) Симонов Иван Михайлович	В) тел галиме, Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы
4) Бодуэн де Куртенэ Иван Александрович	Г) археолог, нумизмат, коллекционер. Аның тупланмасы Казан шәһәре фән-сәнәгать музееның нигезен тәшкил итә
5) Ковалевский Николай Осипович	Д) физиолог. Россия физиологиясендә тәжрибәләр юнәлешен башлап җибәрүчеләрнең берсе, Казан медицина фәнни

	мәктәбендә физиология юнәлешенә нигез салучы

Җавап:

1	2	3	4	5

11. Түбәндә китерелгән төшенчәләргә дөрес билгеләмәләр бирегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 балл, иң югары – 10 балл)

А) Соборное уложение
Җавап: _____
_____

Б) Йомышлы татарлар
Җавап: _____
_____

В) Ханзадәләр
Җавап: _____
_____

Г) Епархия
Җавап: _____
_____

Д) Ясак
Җавап: _____
_____

12. Тарихи вакыйгаларны һәм даталарны туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 балл, иң югары 10 балл)

1) Крепостнойлыкны бетерү турындагы Манифестка җавап йөзеннән, Рус Бизнәсе авылы крестьяннары кузгалышы	А) 1804 ел
2) Казан белән Мәскәүне тимер юл тоташтыра	Б) 1895 ел
3) Казан университеты ачыла	В) 1861 ел
4) Казанда фән һәм сәнәгать музее ачыла	Г) 1893 ел
5) Азия типографиясе ачыла	Д) 1800 ел

Җавап:

1	2	3	4	5

13. Әлеге өзекнең авторы кем? (3 балл)

...Татарлар — горур, шөһрәт сөючән, кунакчыл, акчага хирыс, чиста, үз дәрәҗәсенә карап укымышлы, хорафатларга аз ышанучан, мактанчык, үзара тату, эзләнүчән, беркадәр юмакай, күп нәрсәдә чама белгән, сәүдәгәрлек өчен туган эшчән халык. Шактый еллар буена төрле өязләрдә йөргәндә яисә махсус татар авылларына барып чыкканда миңа аларның гореф-гадәтен, әхлагын, гаилә тормышын якыннан күзәтергә туры килде. Һәр халыкның да яхшы һәм начар ягы була. Шул исәптән татарларның да. Ике гасыр дәвамында буйсындырылып, руслар арасына сибелгәч тә, гореф-гадәтен, йолаларын, горурлыгын саклап кала алган гаҗәеп халык бу.

Җавап: _____

14. Фоторәсемдә татар халкының күренекле шәхесе сурәтләнгән. Ул кем? Әлеге шәхеснең эшчәнлеге турында белгәннәрегезне языгыз.
(Фоторәсемдә кем сурәтләнгән – 1 балл; яшәгән еллары – 1 балл; һәрбер биографик факт өчен – 1 балл, иң югары 10 балл)

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!